ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23 01 2023 г. № 13

**Түбән Кама шәһәре мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре эшчәнлеге өлкәсендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары бирү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мо-билизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре эшчәнлеге өлкәсендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы ни-гезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре әгъзаларына Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсенә караган мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан уздырыла торган музейлар, мәдәни-ял, мәдәни-тамаша һәм мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә башка чараларны бушлай карау хокукы бирергә.

2. Тамашачыларны залда индивидуаль-аерым урыннарга утырту таләпләрен үтәүне исәпкә алып, Түбән Кама шәһәренең муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре тарафыннан мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә мәдәни-ял, мәдәни-тамаша һәм башка чаралар үткәргәндә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләре әгъзасына, әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасына хокук алу өчен, мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре кассасына мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә чара уздыру көненә кадәр 5 календарь көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итәргә кирәк дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022. елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Фе-дерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның хәрби хезмәт узу чорында карала дип билгеләргә.

4. Түбән Кама шәһәре территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренә, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә мәдәни-ял, мәдәни-тамаша чараларын һәм башка чараларны үткәргәндә, әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын бирүне тәкъдим итәргә.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (Мәхмүтов А.Г.):

әлеге карарны Түбән Кама шәһәре ведомство карамагындагы муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм Түбән Кама шәһәре территориясе чикләрендә урнашкан дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләре игътибарына җиткерергә;

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының ведомство карамагындагы оешмалары тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләсенең һәр әгъзасына социаль ярдәм чараларына хокукны раслаучы махсус карталар бирүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мо-билизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын тиешенчә гамәлгә ашыруны контрольдә тотарга.

6. Түбән Кама шәһәренең муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре җитәкчеләренә Россия Федерациясе Президентының «Россия Федера-циясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләренә әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

7. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев